СОВЕТ
НОВОКЫРЛАЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 3, с.Новый Кырлай,
Арский муниципальный район, 422035

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА КЫРЛАЙ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урам, 3 йорт, Яңа Кырлай авылы,
Арча муниципаль районы, 422035

Тел. (84366)56-7-32, факс (84366)56-7-34. E-mail: Nkrl.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы карары**

**25 октябрь 2023 ел** **N1**

**«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Өчиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарга үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Өчиле авылында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге Уставының 25 статьясына нигезләнеп, Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Өчиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын Өчиле авылы, Тукай урамы, 66 йорт адресы буенча 2023 елның 07 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Өчиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын Өчиле авылы, Тукай урамы, 66 йорт адресы буенча 2023 елның 07 ноябрендә 14 сәгать 00 минутка билгеләргә.

1 нче этап: Җиңүнең 65 еллыгы урамы, Яңа урам халкы.

2 нче этап: Тукай урамы халкы.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләге расларга:

«Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Өчиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 15 ноябрендәге

4 номерлы карарына «янгын сүндерү техникасын (ГАЗ-53) сатып алу»ны «янгын сүндерү техникасы-автоцистерна сатып алу»га алыштыру өлешендә үзгәрешләр кертүгә ризамы?

«Әйе» «Каршы»

4. «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Яңа Кырлай авыл җирлегенең Өчиле авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2022 елның 15 ноябрендәге 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп Яңа Кырлай авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны халык күпләп җыела торган урында ТР, Арча районы, Өчиле авылы, Тукай ур., 73 йорт адресы буенча мәгълүмат стендында урнаштырырга, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча Арча муниципаль районының рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

6. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Яңа Кырлай авыл җирлеге башлыгы Г.Г.Сәфәров